ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

28.06.2024 № 586

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 маендагы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 28 маендагы 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 3.3 бүлегендәге 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган мөрәҗәгатьне формат-логик тикшерүне орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьнең һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал гамәлгә ашыра. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьнең корректлы тутырылмаган кыры ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры мөрәҗәгать итүнең электрон формасында хәбәр ителә. Шулай ук мөрәҗәгать итүчегә аның сайлавы буенча, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак, бердәм порталдан файдаланып, орган (оешма) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган машина белән укыла торган форматта электрон документны алу мөмкинлеге тәэмин ителә (алга таба - машина белән укыла торган форматтагы электрон документ)».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин